# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан
Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 13 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында" 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 8 (II өлеш), № 12 (X өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 12 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2012, 17 гыйнвар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның 5 өлешендә "алыну датасын күрсәтеп" сүзләреннән соң ", шулай ук ведомствоара гарызнамәләр буенча алыначак документлар исемлеген күрсәтеп" сүзләрен өстәргә;

2) 8 статьяда:
а) 1 өлештә "әлеге Законның 6 статьясында күрсәтелгән документларның тулы комплекты тапшырылган һәм (яисә) соратып алынган" сүзләрен "тапшыру бурычы гариза бирүчегә йөкләнгән документлар әлеге органга тапшырылган" сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә "орган" сүзеннән соң ", шул исәптән күп функцияле үзәк аша да," сүзләрен өстәргә, түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "Граждан күп функцияле үзәк аша исәпкә алынуы турында гариза тапшырган очракта, гариза бирүче карарны алуның бүтән рәвешен күрсәтмәсә, гражданны исәпкә алу турындагы карар күп функцияле үзәккә җибәрелә.";

3) 23 статьяның 1 өлешендә:

а) түбәндәге эчтәлекле өченче яңа абзац өстәргә:

"дәүләт хакимияте органының, җирле үзидарә органының йә дәүләт хакимияте органы яисә җирле үзидарә органы буйсынуындагы оешманың ведомствоара гарызнамәгә җавабы, әгәр тиешле документ гариза бирүче тарафыннан үз инициативасы буенча тапшырылмаган булса, гражданнарны әлеге Законның 6 статьясы нигезендә торак урыннарына мохтаҗ сыйфатында исәпкә алу өчен кирәкле документ һәм (яисә) мәгълүмат булмавын таныклый, моңа мондый соратып алына торган документның яисә мәгълүматның шушы органнар яисә оешмалар карамагында булмавы тиешле гражданнарның торак урыннарына мохтаҗлар сыйфатында исәптә тору хокукын раслый торган очраклар керми;";

б) өченче һәм дүртенче абзацларны тиешенчә дүртенче һәм бишенче абзацлар дип санарга;

4) 25 статьяның 1 өлешендәге алтынчы абзацына ", моңа өч һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнар керми" сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 1 – 3 пунктларыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 – 3 пунктлары 2013 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. "Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында" 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (әлеге Закон редакциясендә) 25 статьясындагы 1 өлешенең алтынчы абзацы нигезләмәләренең гамәли көче 2011 елның 17 июненнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2012 елның 29 сентябре
№ 68-ТРЗ